Татарстан Республикасы
Арча муниципаль районының
Арча шәһәр муниципаль берәмлеге
Арча шәһәр
башкарма комитеты

422000, Арча ш. Совет мәйданы, 27
тел. 3-16-25, 3-12-35

Муниципальное образование
город Арск
Арского муниципального района
Республики Татарстан
исполнительный комитет
города Арск
422000, г. Арск, площадь Советская, 27
тел. 3-16-25, 3-12-35

# КАРАР

« 07 » декабрь 2018 ел № 241

**Яңа ел бәйрәме чаралары чорына транспорт чаралары хәрәкәтен чикләү турында**

«Россия Федерациясендә автомобиль юллары һәм юл эшчәнлеге турында» 2007 елның 8 ноябрендәге 257-ФЗ номерлы Федераль законның 30 статьясына таянып, юл-транспорт һәлакәтләрен кисәтү, юл хәрәкәте иминлеген тәэмин итү һәм Яңа ел бәйрәмнәре чорында җәяүлеләрне бәрдерүне булдырмау максатларында Арча шәһәре башкарма комитеты КАРАР бирде:

1. 2028 елның 22 декабреннән 2019 елның 13 гыйнварына кадәр Арча шәһәренең түбәндәге урыннарында гражданнар күпләп җыела торган урыннарга автотранспортның рөхсәтсез йөрү мөмкинлеген булдырмау максатларында «Хәрәкәт тыела» 3.2 юл билгесен куярга:

1.1 Вахитов һәм Первомайская урамнары киселешендә, Үзәк стадионга таба хәрәкәт юнәлешендә – 1 билге;

1.2 Ежков урамында, 9 нчы йорт каршында, Үзәк стадионга таба хәрәкәт юнәлешендә - 1 билге;

1.3 Тау асты урамы тоташкан урында Арча шәһәренең тимер юл станциясенә алып баручы автомобиль юлына таба, хәрәкәт юнәлешендә – 1 билге.

1.4 Әлеге юл билгесенең гамәлдә булуы массакүләм бәйрәм чараларын оештыруда һәм үткәрүдә катнашкан һәм тыю зонасында халыкка хезмәт күрсәтүче транспорт чараларына кагылмый.

2. Тәкъдим итәргә:

2.1 «Жилкомбытсервис» ҖЧҖнә әлеге карар нигезендә Арча шәһәре юлларында күрсәтелгән юл билгеләрен 2018 елның 22 декабренә кадәр урнаштырырга;

2.2 Россия Эчке эшләр министрлыгының Арча районы буенча ЮХИДИ идарәсенә әлеге участокта юл хәрәкәте иминлеген контрольдә тотарга.

3. Әлеге карар игълан ителгән көннән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Арча шәһәре Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары Л.Р.Йосыповка йөкләргә.

Арча шәһәре башкарма
комитеты җитәкчесе Р. Ф. Касыймов